# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 29 ноябрендә 11 сәгатьтә 00 минутта, булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2022 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- җирлек торак пунктларында су челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 90 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 57, бу 63 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 57 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- җирлек торак пунктларында су челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М. Емельянова